МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.03.2023 Казан ш. № 49-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Энергетика һәм энергетика ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында» 2022 елның 21 мартындагы 48-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 4 декабрендәге 654 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 30 декабрендәге 1473 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган үзгәрешләргә ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Энергетика һәм энергетика ресурслары

нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында» 2022 елның 21 мартындагы 48-ОД номерлы боерыгына (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең I бүлегендәге 2 пунктының 2 абзацында «Татарстан Республикасында энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» сүзләрен «2022-2026 елларга Татарстан Республикасында энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекнең 11 пунктында «6500» саннарын «5000» саннарына алмаштырырга;

2. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чорда дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Җыелма бүлеккә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында әлеге боерыкны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары М.Ф.Миңнебаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В.Коробченко